| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |

«28» декабрь, 2023 ел      Алабуга шәһәре      № 317

Алабуга муниципаль районының «Мурзиха авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше Кодексы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы законы нигезендә һәм 2023 елның 14 декабрендәге «Мурзиха авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Алабуга районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Мурзиха авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр төзелеше һәм инфраструктура үсеше, туризм мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары      Р.Л. Исланов